ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2025 г.Лениногорск № 1005

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 8 октябрендәге 873 номерлы карары белән расланган махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә, шулай ук «Лениногорск балалар йорты»ДВУдан ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә, өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Өстәмә социаль ярдәм алучылар категорияләрен киңәйтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 8 октябрендәге 873 номерлы карары белән расланган махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән

балаларның гаиләләренә, шулай ук «Лениногорск балалар йорты»ДБУдан ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга  Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә, өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Балаларга түләүсез йөрү хокукын бирү өчен уку йортларыннан һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Лениногорск балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесеннән гаризалар (2 нче кушымта формасы буенча) Мәгариф идарәсендә эш көннәрендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Лениногорск шәһәре, Шашин пр., 22 йорт.»;

Тәртипкә кушымта нигезендә 2 нче кушымта өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

М.Г. Якупов
5-15-41

2 нче кушымта
Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә, шулай ук «Лениногорск балалар йорты»ДБУдан ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә, өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибенә
2025 елның _______нән __ номерлы

____________---нән
Ф.И.АИ. (кыскартуларсыз)
____________________сериясе__№
(шәхесне таныклаучы документ: документ төре) бирелде _______________________
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
Адрес:
(яшәү (тору) урыны буенча теркәү)
______________________________________
(шул исәптән факттагы яшәү урыны адресы)
тел.:
электрон адрес:

ГАРИЗА
Миңа (яки балигъ булмаганга) бирүегезне үтенәм.

____________________________________________________________________________
(Социаль ярдәм чараларын алучы ФИАи)
өстәмә социаль ярдәм:

*1 вариант-Лениногорск муниципаль районының шәһәр яны маршрутларында автомобиль транспортында (таксидан тыш), җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча түләүсез йөрү рәвешендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре,*

*2 вариант - «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучыны*

*3 вариант - «Лениногорск балалар йорты» ДБУдан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, теркәлгән документлар нигезендә.*

Әлеге өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында минем шәхси мәгълүматларны (минем балигъ булмаган баламның шәхси мәгълүматларын) эшкәртүгә ризалыгымны бирәм. Мин биргән белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык турында кисәтеп куям.

Кушымта:

1. ___________________________________________________________________
2. ___________________________________________________________________
3.

«______«_______________________________________________20_________ел

/____________________/

(имза) ФИАи»